# Гафу ит син

Рамил Чурагулов сүзләре

Фәнир Галимов көе




1

Маңгайларга сала буразналар
Башка тешкән хәсрәт кайгылар.
Кайгы хәсрәтләрне таратучы
Син янымда якын кешем бар.

*Кушымта:*

Гафу ит син мине, гафу ит син
Саксыз сузем белән рәнжетсәм.
Бер көн уйламаган адым ясап
Кайнар йөрәгеңне өшетсәм.

2

Көзгеләргә карап уфтанма әлә,
Ямансулап яшьлек узганга.
Картлык безгә тимәй урап узар
Без хисләргә тугры булганда.

3

Чал чәчләрең миңа хәтерләтер,
Шау чәчәкле ап-ак язларны.
Сөю шарапларын эчеп куейк
Тамчыгача безгә язганын.